**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**01.07.2015** **№ 456-п**

**Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре аларны билгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында**

2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны яки булдыруны, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 8 мартындагы “Коррупциягә каршы көрәш буенча аерым мәсьәләләр турында” 120 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 08 июнендәге “Аларны билгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” ПУ-542 номерлы Указын үтәү максатында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре аларны

биләгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Документлар башкаруны контрольдә тоту бүлегенә (Г.Р.Ханнанова) боерыкны Министрлыкның Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К.Сәлимгәрәев) боерыкның күчермәсен, аны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алганнан соң өч көнлек срокта, Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр А.Г.Сидоров

Татарстан Республикасы Экология һәм
табигый ресурслар министрлыгының
2015 елның 01.007.
456-п номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре аларны биләгәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачарга яки булдырырга, тере акча чаралары һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга ярамый торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге**

**Дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының иң өлкән төркеме:**

министрның беренче урынбасары,

министр урынбасары.